«АТНА ВАКЫЙГАЛАРЫ»
№ 16 (323) | 24-30 апрель 2020 ел



# Эпидемиянең башы гына әле

## Эпидемия кайчан тәмамланыр? Бу - бөтен кешене кызыксындыра һәм борчый торган сорау.

Александра **ДАВЫДОВА**

**Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитетының Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы Владимир Жаворонков фикеренчә, киләчәктәге вәзгыятьне ике төрле (Кытайдагы һәм Италиядәге кебек) фаразларга була.**



Фото - tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республикада коронавирус инфекциясе таралуын кисәтү, хастаханәләрне һәм табибларның авыруларны кабул итәргә әзерлеген тикшереп тора. «Татарстанда коронавируска бәйле вәзгыятьне контрольдә тотабыз», - диде Президент.

Кытайда башланган COVID-19 коронавирусы бөтен дөнья буйлап таралуын дәвам итә. Европада Италия иң нык зыян күргән илләрнең берсе булды, диләр.

– Эпидемия башлангач, Кытай кырыс карантин чараларын күрде, ә Италия моны эшли алмады. Нәтиҗәдә, Кытайда вәзгыять уңай якка үзгәрде һәм икътисадын яңадан торгыза башлады, ә Италиядә инфекция таралуын дәвам итә, үлем очраклары да шактый. Россия һәм Татарстан, чит илләр тәҗрибәсенә таянып, башта ук кайбер кисәтү чараларын күрергә өлгерде. Авыручылар санын киметү өчен халыкның урамда йөрүен чикләү дөрес карар булды, – ди Владимир Жаворонков.

**Авыручылар саны артачакмы?**

Дәүләт хакимияте вирусның ничек таралачагын фаразлап, халыкны һәм медицина тармагын алдагы хәлләргә әзерләргә бурычлы.

– Бездә коронавирус йоктыручылар күп түгел дип җиңел суларга иртәрәк әле. Республика эпидемиянең башында гына тора. Инфекция йоктыручылар саны арта барачак һәм авыруның катлаулы формалары да күзәтелергә мөмкин. Кайбер очракларда авыру бик тиз азып китә, менә шуннан куркырга кирәк тә, – ди сәламәтлек саклау министры урынбасары.

Эпидемияне мөмкин кадәр исән-имин үткәреп җибәрү өчен кешеләр изоляция режимын бозмауның әһәмиятен аңларга тиеш, бу вирус – шаяру түгел, дип кисәтә табиблар.

– Без авыруның иң югары ноктасын көтәбез. Вирусологлар һәм эпидемиологларның фикере уртак – бу инфекция кешелеккә янаудан туктасын өчен халыкның якынча 70 проценты авырырга тиеш. Димәк, халыкның күп өлеше чирләячәгенә әзер булырга кирәк. Безнең төп бурыч – инфекция йоктыручылар саны һәм авыруның авыр формалары кисәк артуына юл куймау. Татарстанның сәламәтлек саклау системасы коронавирус инфекциясе таралуының теләсә нинди сценариена әзер. Италия нәкъ менә кинәт кенә бик күп кешенең авырып китүеннән һәм сәламәтлек саклау системасының моңа әзер булмавыннан кыен хәлдә калды да инде. Шуңа күрә карантин, изоляция чаралары гаять мөһим шарт булып тора. Халык бу чир миңа кагылмый дип уйларга тиеш түгел, инфекцияне таратмау турында сүз бара. Бигрәк тә өлкән яшьтәге кешеләр урамга чыгып йөрмәскә тиеш, – дип кисәтте Владимир Жаворонков.

Россиядә беренче очрак – 31 гыйнварда, Татарстанда исә 15 мартта теркәлде. Бу атна уртасына Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны 300гә якынлашты. Ә Россия буенча әлеге сан 50 меңнән артып китте. Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсе җитәкчесе Марина Патяшина хәбәр иткәнчә, Татарстанда соңгы көннәрдә берничә предприятиедә коронавирус очраклары теркәлгән. Гадәттә, бер хезмәткәр чирләп, башкаларга да йоктырган һәм алары өйләренә ияртеп кайткан. Марина Патяшина күрше төбәкләрдәге хәвефле күрсәткечләр арта башлавына игътибар юнәлтте. Шуңа күрә читтән эшчеләр чакыруга сак карарга киңәш итте.

---

Кулланучы хәбәрләре


# Төшке ашны – өйгә

**«Бүген карантин шартларында азык-төлеккә заказ бирү һәм әзер ризыкны өйгә китерү хезмәтләре бик актуаль. Үзебезне очраклы рәвештә коронавирус йоктырудан саклау өчен, без дә ирем белән азык-төлекне дистанцион юл белән сатып алырга булдык. Әлеге уңайдан нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәк?**

**Наталья Р.»**

Әгәр изоляция режимында азык-төлек продуктларына заказ бирергә һәм әзер ризыкны өйгә китерү хезмәтеннән файдаланырга телисез икән, бу очракта иң гади кагыйдәләрне үтәргә киңәш итәбез:

✔ Әзер ризык яки азык-төлек салынган пакетны ачар алдыннан кулыгызны яхшылап юыгыз. Чөнки сез кулыгызда акча тоткансыз, түләү терминалына кагылгансыз яки пластик карточкагызны курьерга биргәнсез.



✔ Әгәр тиз бозыла торган азык-төлек продуктларына заказ биргәнсез икән, аларны сумкасыыткыч яки термопакетта китерергә тиешләр. Бу таләп үтәлмәгән очракта, өйгә китергән азык-төлектән баш тарта аласыз.

✔ Ризыкның яраклылык вакытын, кабының ачылмаганлыгын, металл консерв банкаларының капкачларында яньчелгән һәм кабарган урыннар юкмы икәнлеген яхшылап тикшерегез. Бераз гына яньчелгән урын күренсә дә, бу банканың герметиклыгын бозарга яки авыр металл тозларының ризыкка эләгүенә сәбәп булырга һәм аны ашап агулануга китерергә мөмкин. Бозылган товарны сатучыга кайтарып бирә аласыз.

✔ Яшелчә һәм җиләк-җимешнең шиңгән, күгәргән һәм черегән урыннары булмаска тиеш. Бу ризык ашарга яраксыз дип санала һәм аннан шулай ук баш тарта аласыз.

✔ Чи һәм кулланууга әзер продукцияне бер үк пакетка салып китерергә тиеш түгелләр. Аерым төркемгә караган һәр продуктны, шул исәптән сәнәгать товарларын да төрле пакетларга салу иң оптималь вариант булачак.

**ИГЪТИБАР!**
**Әгәр хезмәт сыйфатсыз күрсәтелгән яки сезгә бозылган азык-төлек китергәннәр икән, бу очракта Роспотребнадзор сайтында әлеге сәүдә предприятиеләрен һәм алар тарафыннан җибәрелгән хилафлыкларны күрсәтеп, мөрәҗәгать калдыра аласыз. Шулай ук мөрәҗәгать тулырак булсын һәм аны үз вакытында карасыннар өчен, продуктлар өчен акча түләнгәнлеген раслый торган документлар да тәкъдим итәргә мөмкин. Сәламәтлек һәм уңышлар телләп калабыз!**

# Товарны ничек кире кайтарырга?

**Бүген күп кенә гражданнар өчен кибеттән әйбер сатып алу чын мәгънәсендә проблемага әверелде. Күп кенә кибетләр ябылды һәм товарны кире кайтарып бирү мөмкин дә түгел. Изоляция шартларында өйдә утыручы кешеләрнең күпчелеге кирәкле әйберне дистанцион юл белән сатып ала һәм еш кына, мисал өчен, азык-төлек булмаган товарның үлчәме яки төсе туры килми. Алар алдында товарны кире кайтарып бирү проблемасы килеп басты.**

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 26.1нче маддәсе нигезендә, сатып алучы товардан аны тапшырганчыга кадәр теләсә кайсы вакытта һәм кабул итеп алганнан соң җиде көн эчендә баш тарта ала. Әгәр сатучы, товарны китергән вакытта, сатып алучыга товар, дистанцион юл белән сатып алынган товарны кире кайтару тәртибе һәм вакыты турында язма рәвештә мәгълүмат бирмәгән икән, сатып алучы товарны тапшырган вакыттан алып өч ай эчендә аннан баш тартырга хокуклы.

Әгәр тиешле сыйфаттагы товар дистанцион юл белән ял атнасы кертелгәнчегә кадәр сатып алынган һәм үзенең формасы, зурлыгы, фасоны, төсе, үлчәме яки комплектациясе буенча туры килмәгән икән, сатып алучы югарыда күрсәтелгән Законның 25нче маддәсе нигезендә аны, сатып алган көнне санамыйча, әмма ял көннәре тәмамланганнан соң ундүрт көн эчендә алыштырырга хокуклы. Бу очракта кулланучыга тиешле таләп белән сатучыга язма рәвештә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

**! Бүгенге кануннар тарихында әле мондый хәл күзәтелмә-гәнлектән, «Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы Законда әлеге моментка килеп туган вәзгыять хакында бернидә дә әйтелми.**

1994 елның 30 ноябрендә кабул ителгән РФ Гражданнар кодексының 1нче өлеше 193нче маддәсе нигезендә, әгәр срокның соңгы көне ял көненә туры килә икән, аннан соң килгән якындагы эш көне срокның тәмамлану көне дип санала. Ягъни сез үз таләпләрегезне кибет үзенең эшчәнлеген тулы күләмдә алып бара башлагач кына белдерә аласыз.

**Сәламәтлегегезне һәм акчагызны саклагыз. Дөньяда килеп туган вәзгыятькә бәйле рәвештә, сезнең таләпләрне бик тиз генә карамаска, ә акчагызны тагын да соңрак кайтарып бирергә мөмкиннәр.**

